РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

15 ноябрь, 2024 ел Кукмара ш. № 276

Кукмара район Советының 2005 елның 22 декабрендәге 28 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кукмара район Советының 2005 елның 22 декабрендәге 28 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.11. Палатаның урнашу урыны (адресы): Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара ш., Ленин ур., 15 й.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район башлыгы С.Д. Димитриев